Azatlıq Radiosı

ЯҢАЛЫКЛАР

# Turkish Airlines якын көннәргә Казаннан Истанбул һәм Антальяга иртәнге очышларны туктатты

әле генә




Иллюстратив фото

**Дрон һөҗүме куркынычы сәбәпле соңгы көннәрдә Казан һава аланы иртән очышларны җибәрми һәм кабул итми**

**Turkish Airlines якын көннәргә Казаннан Истанбул һәм Антальяга иртәнге очышларны туктатты**

Моңа һава киңлеген куллануга кертелгән чикләүләр сәбәп булган. Чөнки дроннар һөҗүме куркынычы сәбәпле өч көн рәттән Казанда һава аланнары вакытлыча ябылып торды.

Шул сәбәпле кичә өзеклекләр башланган. Төркиядән килгән ТК-3062 (Истанбул)

һәм TK-429 (Анталья) рейслары "ковер" планы кертелү сәбәпле Тифлискә төшәргә мәҗбүр булган. TK-3062 рейсы нәтиҗәдә Казанга 13,5 сәгать соңарып килеп җиткән, ә TK-429 бөтенләй борылып кире Истанбулга кайтып киткән.

Бу тоткарлыклар сәбәпле, рейсларны гамәлдән чыгарганнар.

TK-3063 рейсы Антальяга 14 сәгатькә соңарып, TK-3039 алты сәгатькә соңарып очып киткән, ә ә TK-430 рейсы бөтенләй өч көнгә гамәлдән чыгарылган.

8 августтан соң TK-3033 (Анталья), TK-429 (Истанбул) һәм TK-30323 (Анталья) рейслары очачакмы-юкмы әлегә билгесез.

Turkish Airlines ярдәм хезмәтендә бу юнәлешләргә алдагы вазгыятьне фаразлый алмауларын белдергәннәр. Шулай да юлчыларны башка рейсларга күчерергә вәгъдә иткәннәр.

TOURDOM.RU хәбәр итүенчә, Истанбулга барырга тиеш булганнарга TK-6890 рейсы белән 19:05 сәгатьтә очу тәкъдим ителә. Бүген иртән Антальяга оча алмаган юлчыларга TK-3023 рейсы белән 16:05 сәгатьтә очу мөмкинлеге тәкъдим ителә. Иртәгә бу юнәлештә ике рейс планлаштырылган TK-3039 — 13:20 сәгатьтә, TK-3023 — 15:10 сәгатьтә.

- Дроннар аркасында Казан һава аланында очкычларны кабул итү яки очыртып җибәрүгә чикләүләр кертелә.
- Татарстанга дроннар һөҗүме булган чакта очкычларның маршрутын үзгәртү һава ширкәтләренә өстәмә чыгымнар тудыра.
- Бүген Казан һава аланында 50дән артык очыш тоткарланды.

🛑 **Русиядә Азатлык сайты томаланды, нишләргә?Безнең кулланма.**
🌐 **Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар сакланган